СОВЕТ САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
422060, Республика Татарстан, Сабинский район, п.г.т. Богатые Сабы, ул. Г.Закирова, 52

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ
422060, Татарстан Республикасы, Саба районы, Байлар Сабасы ш.т.п., Г.Закиров урамы, 52 йорт

тел. (84362) 2-31-33, 2-31-44, факс (84362) 2-31-74, e-mail: saba@tatar.ru, www.saby.tatarstan.ru

№ 45 от 24.02.2021

на № _от ________

# К А Р А Р

Саба муниципаль районының 2020 нче елда социаль-икътисади үсеш нәтиҗәләре һәм 2021 нче елга бурычлары турында

Саба муниципаль районы Башлыгы Р. Н. Миннихановның 2020 нче елда Саба муниципаль районының социаль-икътисади үсеш нәтиҗәләре һәм 2021 нче елга бурычлары турындагы докладын тыңлап фикер алышканнан соң, Саба муниципаль районы Советы 2021 нче елга төп бурыч-финанс-икътисад эшчәнлегенең тотрыклы нәтиҗәләренә ирешү; халыкның тормышы һәм эше өчен уңайлы һәм имин шартлар тудыру, эшчәнлекнең барлык өлкәләренә цифрлаштыруны кертү, сәнәгать робототехникасын үстерү, авыл хуҗалыгын модернизацияләү, сәнәгатьне модернизацияләү, инвесторлар җәлеп итү, кече һәм урта бизнесны киңәйтү; бюджет керемнәрен тәэмин итү, социаль өлкәгә ярдәм итү, милләтара, динара һәм гражданлык татулыгын ныгыту, районда яшәүче халыкларның милли һәм мәдәни тиңдәшлеген саклап калу өчен шартлар тудыру, җирле үзидарәне үстерү өчен шартлар тудыру, дип билгеләп үтә.

Югарыда бәян ителгәннәрдән чыгып, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Советы КАРАР БИРДЕ:

1. Саба муниципаль районы Башлыгы Р. Н.Миннихановның 2020 нче елда Саба муниципаль районының социаль-икътисади үсеш нәтиҗәләре һәм 2021 нче елга бурычлары турындагы докладын игътибарга алырга.

2. Саба муниципаль районы Башкарма комитетына 2021 елның 1 апреленә кадәр докладта әйтелгән бурычларны тормышка ашыру буенча чаралар планын эшләргә һәм расларга һәм аның үтәлешен тикшереп торырга.

3. Шәһәр һәм авыл җирлекләре башлыкларына түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

- территорияне, шәхси ярдәмче хуҗалыкларны комплекслы социаль-икътисадый үстерүгә аерым игътибар бирергә;

- эшсезлекне, халыкның формаль булмаган мәшгульлеген киметү буенча эшне көчәйтергә;

- кече һәм урта бизнесны үстерү һәм үзара салым акчаларын куллану юлы белән җирлек бюджетына өстәмә акчалар җәлеп итү буенча максатчан эш алып барырга;

- дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрне электрон рәвештә күрсәтүгә игътибарны арттырырга;

- яшьләрне авылда калдыру өчен кредит бирү һәм торак төзелеше өлкәсендә гамәлгә ашырыла торган программаларның мөмкинлекләреннән күбрәк файдаланырга;

- халыкның тормыш дәрәҗәсен киметүне булдырмау һәм гражданнарның социаль хезмәтләрдән бертигез файдалануын тәэмин итү буенча чаралар күрергә;

- торак пунктларны төзекләндерү, яшелләндерү, җирлек территорияләрендә экологик куркынычсызлыкны тәэмин итү буенча эшне дәвам итәргә.

4. Әлеге карарны һәм Саба муниципаль районы Башлыгының докладын Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының http://saby.tatarstan.ru рәсми сайтында урнаштырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Саба муниципаль районы Башлыгы урынбасары Р.Р. Закирҗановка йөкләргә.

Саба муниципаль
районы Башлыгы Р. Н. Минниханов